ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НОВОШЕШМИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯҢА ЧИШМӘ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2022 елның «07» ноябреннән № 325

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларына юл сервисы объектларын тоташтыру хезмәтләре бәясен һәм исемлеген раслау турында

«Россия Федерациясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2007 елның 08 ноябрендәге 257-ФЗ номерлы Федераль законның нигезендә, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Яңа Чишмә муниципаль районында гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына юл сервисы объектларын кушу буенча хезмәт күрсәтүләрнең бәясен һәм исемлеген 1 нче кушымта нигезендә расларга.

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат–телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында http://novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктур үсеш буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче Р.Р. Фасахов

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
Башкарма комитетының
2022 елның «07» ноябреннән
325 номерлы карары белән
расланган

Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларына юл сервисы объектларын кушу буенча хезмәт күрсәтүләрнең бәясе һәм исемлеге

| № т/б | Хезмәтнең атамасы | III-IV категорияле юллар өчен бәя, сум |
|---|---|---|
| 1. | Кафе, ресторан, кибет кушу | 35 803,68 |
| 2. | Техник хезмәт күрсәтү пунктын (шиномонтаж) кушу | 30 921,36 |
| 3. | Техник хезмәт күрсәтү пунктын кушу (ремонтлау, юу) | 39 058,56 |
| 4. | Базар (сәүдәнең оешкан нокталары) кушу | 39 058,56 |
| 5. | Транспорт чараларының туктау урыннарын һәм тукталыш урыннарын (юл сервисы объектларында) кушу | 26 039,04 |
| 6. | Автозаправка станцияләрен кушу | 47 195,76 |
| 7. | Юл сервисы комплексын кушу | 47 195,76 |
| 8. | Автозаправка станциясе белән юл сервисы комплексын кушу | 56 960,4 |
| 9. | Сәүдә комплексын кушу | 47 195,76 |
| 10. | Йөк автотранспортына хезмәт күрсәтүче биналар һәм корылмаларны (йөк автостанцияләре, терминаллар, түләүле машина туктау урыннары һ.б.) кушу. | 52 078,08 |